РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

НИЖНЕШИТЦИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422067, Республика Татарстан, Сабинский район, с. Нижние Шитцы, ул. Тукая, 15
тел. (84362) 46-4-42

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШЫТСУ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422067, Татарстан Республикасы, Саба районы, Түбән Шытсу авылы, Тукай урамы, 15
тел. (84362) 46-4-42

Не-mail: shic.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

12.08.2024 — №24

Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының 2019 елның 6 маендагы 22 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 6 маендагы 22 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пункт таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңнән артык кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 23700 | 25000 |
| бухгалтер | | 22500 |

».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shitsi адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Түбән Шытсу авыл
җирлеге башлыгы

Б.М.Мәүлетов